МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.01.2020 г. Казань № под-97/20

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2018 елның 30 июлендәге под-1161/18 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы ведомствосындагы дәүләт мәгариф оешмалары җитәкчеләренә һәм әлеге вазыйфага кандидатларга аттестация үткәрү турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында

Норматив хокукый актларны федераль законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы ведомствосындагы дәүләт мәгариф оешмалары җитәкчеләренә һәм әлеге вазыйфага кандидатларга аттестация үткәрү турында нигезләмә раслау хакында» 2018 елның 30 июлендәге под-1161/18 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы ведомствосындагы дәүләт мәгариф оешмалары җитәкчеләренә һәм әлеге вазыйфага кандидатларга аттестация үткәрү турындагы нигезләмәнең 3.3 пунктының икенче абзацына, аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«хезмәт кенәгәсенең күчермәсе яисә хезмәт эшчәнлеге һәм хезмәт стажы турында Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $66^{1}$ статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган белешмәләр;».

2. Кадрлар сәясәте бүлеге җитәкчесенә (Л.С.Әмирова) боерыкны имзаланганнан соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек срокта Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алу өчен җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр вазыйфаларын башкаручы И.Г. Хәдиуллин